# **Дус булып яшик**

1. Болытлар дус һава белән,
Яңгыр - җир белән.
Күңелкәем моң белән дус,
Ә мин җыр белән.

Кушымта:
Дус булып яшикче җирдә
Шатланып, көлеп.
Тынычлыкның һәм дуслыкның
Кадерен белеп.

2. Елгалар дус яры белән,
Былбыл - тал белән.
Бал кортлары чәчкә белән,
Аю - бал белән.

3. Җиләкләр дус алан белән,
Кош - тугай белән.
Күбәләкләр- гөлләр белән,
Кыр - тургай белән.
Һәрвакытта дус булырбыз
Без "Тургай" белән.